ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2018 Казан ш. № 3-8/э

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарында электр энергиясен (куәтен) бирүче "Татэнергосбыт" акционер җәмгыятенең 2019 елга гарантия бирә торган электр энергиясен җибәрүченең сату бәясенә өстәмә хак билгеләү турында

"Электр энергетикасы турында" 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергетикасында җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында" 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең "Гарантия бирә торган электр энергиясен җибәрүченең сату бәясенә өстәмә хакларны аналогларны чагыштыру алымын кулланып исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2017 елның 21 ноябрендәге 1554/17 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарында электр энергиясен (куәтен) бирүче "Татэнергосбыт" акционер җәмгыятенең гарантия бирә торган электр энергиясен җибәрүченең сату бәясенә өстәмә хакын 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча<br>дәүләт комитетының<br>2018 елның 7 декабрендәге 3-8/э номерлы<br>карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарында электр энергиясен (куәтен) бирүче "Татэнергосбыт" акционер җәмгыятенең гарантия бирә торган электр энергиясен җибәрүченең сату бәясенә өстәмә хакы, 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр календарь бүленеш белән (тарифларны күрсәткәндә НДС исәпкә алынмаган)

1 нче таблица

| т/б № | Татарстан Республикасында гарантия бирә торган җибәрүченең исеме | Сату бәясенә өстәмә хак | |
|---|---|---|---|
| | | кулланучыларның "халык" тариф төркеме һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категорияләре | |
| | | сум/кВт.сәг. | |
| | | 1 нче яртыеллык | 2 нче яртыеллык |
| 1. | "Татэнергосбыт" акционер җәмгыяте | 0,3299 | 0,3628 |

2 нче таблица

| т/б № | Татарстан Республикасында гарантия бирә торган җибәрүченең исеме | Сату бәясенә өстәмә хак | |
|---|---|---|---|
| | | кулланучыларның "электр энергиясен югалтуларны компенсацияләү өчен электр энергиясен сатып алучы челтәр оешмалар" тариф төркеме | |
| | | сум/кВт.сәг. | |
| | | 1 нче яртыеллык | 2 нче яртыеллык |
| 1. | "Татэнергосбыт" акционер җәмгыяте | 0,0751 | 0,0827 |

3 нче таблица

| т/б № | Татарстан Республикасында гарантия бирә торган җибәрүченең исеме | Сату бәясенә өстәмә хак | |
|---|---|---|---|
| | | "башка кулланучылар" тариф төркеме | |
| | | сум/кВт.сәг. | сум/кВт.сәг. |
| | | 1 нче яртыеллык | 2 нче яртыеллык |
| 1. | "Татэнергосбыт" акционер җәмгыяте | СН $_{\text{670 кВт кадәр}}$ = 0,1062 | СН $_{\text{670 кВт кадәр}}$ = 0,1704 |
| | | СН $_{\text{670 кВт алып 10 МВт кадәр}}$ = =0,0508 | СН $_{\text{670 кВт алып 10 МВт кадәр}}$ = = 0,0568 |
| | | СН $_{\text{10 МВт күбрәк}}$ = =0,0354 | СН $_{\text{10 МВт күбрәк}}$ = = 0,0568 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге